Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы Карары

**20 гыйнвар 2020 ел** **№ 127**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге
«Җир салымы турында" 112 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 112 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
**1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
2.2. 0,12 процент Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары яки индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегеннән һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);
**1.2. 4.2 пунктта сүзтезмәне төшереп калдырырга**:
«яки шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар».
**1.3. 5 пунктны төшереп калдырырга.**
2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.
3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында:pravo.tatarstan.ru веб –адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: А.В.Фатыхова

Совет Нижнеберескинского сельского поселения
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000476